СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2020 Әгерҗе шәһәре № 4-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 6 бүлекнең 1, 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә төзелә торган, Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе белән Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органындагы вазыйфа».

«3. Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре кулланыла.».

1.2. 15 кисәккә 4 пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр урынбасары булган муниципаль хезмәткәргә, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмас өчен, тиешле вазыйфаны биләгән чорда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклау тыела.».

1.3. 19 бүлекнең 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;».

1.4. 19 бүлекнең 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ;».

1.5. Нигезләмәнең 28 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 19.1 пункт өстәргә:

«19.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.».

1.6. 34 бүлекнең 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 28 декабрендәге 33-7 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.2 пунктчасы;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 гыйнварындагы 44-3 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.3, 1.4 пунктчалары.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2 пунктчасы 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Ә. Закировага йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев